СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

« 03 » апрель 2025 ел № 329

**2025 һәм 2026 елларда Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 494-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 10 октябрендәге “Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә һәм Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә кергәндә белешмәләр бирүнең һәм аларны актуальләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында” 870 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы белән, Арча район Советы **карар чыгарды:**

1. 2025 һәм 2026 елларда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Арча муниципаль районы муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми дип билгеләргә.

1.1. Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куелганда әлеге карарның 1 пункты кулланылмы.

2. Арча район Советының 2005 елның 31 октябрендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы

нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә (2014 елның 19 сентябрендәге 286нчы номерлы, 2020 елның 13 сентябрендәге 3нче номерлы, 2022 елның 26 маендагы 147нче номерлы үзгәрешләр белән) һәм 1 нче кушымтаны яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштырып бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 3 апреленнән үз көченә керә.

Арча муниципаль район
башлыгы урынбасары,
Арча район Советы Рәисе урынбасары А.Ф.Мөхәмәтова

Арча район Советы карарына кушымта

«03» апрель 2025 ел №329

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә һәм Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә керү өчен**
**АНКЕТА**
(Федераль куркынычсызлык хезмәте органнарына контракт буенча хәрби хезмәткә керүче затлар тутырмый)

| | |
|---|---|
| 1. Фамилия ______________________ | Фотосурәт өчен урын |
| Исем ______________________ | |
| Әтисенең исеме ______________________ | |

| | |
|---|---|
| 2. Фамилия, исем, әтиегезнең исемен үзгәрткән булсагыз, элекке фамилия, исем, әтиегезнең исемен, аларның үзгәрү сәбәбен, мондый үзгәрешне раслаучы документның төрен, аның сериясен һәм номерын, документны биргән органның исемен, аны бирү датасын күрсәтегез | |
| 3. Туган көне, ае, елы. Паспорт нигезендә күрсәтелә. Әгәр паспорттагы мәгълүмат туу турындагы таныклыктагы мәгълүмат белән туры килмәсә, туу турындагы таныклык нигезендә өстәмә рәвештә мәгълүмат күрсәтелә | |
| 4. Туган урыны (торак пункт, Россия Федерациясе субъекты, чит дәүләтнең административ-территориаль берәмлеге, дәүләт, Дәүләт-территориаль берәмлеге, элеккеге СССРның административ-территориаль берәмлеге). Паспорт нигезендә күрсәтелә. Әгәр паспорттагы мәгълүмат туу турындагы таныклыктагы мәгълүмат белән туры килмәсә, туу турындагы таныклык нигезендә өстәмә рәвештә мәгълүмат күрсәтелә | |

| | |
|---|---|
| 5. Паспорт яисә аны алмаштыручы документ: документның төре, аның сериясе һәм номеры, документны биргән органның исеме, аны бирү датасы, бүлекчә коды | |
| 6. Гражданлык. Әгәр үзгәрткәнсез икән, үзгәрешнең датасын һәм сәбәбен, элеккеге гражданлыкны, башка дәүләт гражданлыгыннан чыгуны (элеккеге СССРның союздаш республикаларын да кертеп) рәсмиләштерелгәнне, чыгу датасын һәм нигезен (югалту) күрсәтегез. Әгәр Россия Федерациясе гражданлыгыннан тыш чит ил гражданлыгыгыз булса, күрсәтегез. | |
| 7. Яшәү рөхсәте һәм (яисә) чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документыгыз (аның гамәлдә булу срогы) булганмы, даими яшәү урынына башка дәүләткә (гариза бирү датасы, нинди дәүләт) чыгу (керү) турында үтенеч белән мөрәҗәгать иткәнегез бармы (булганмы) | |
| 8. Индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (булган очракта) | |
| 9. Мәҗбүри медицина иминияте полисы (булган очракта) | |
| 10. Салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта) | |
| 11. Белеме: белем дәрәҗәсе, белем турында һәм (яисә) квалификация турында документның төре, аның сериясе һәм номеры, документны биргән оешманың исеме, аны бирү датасы, укыту рәвеше, белгечлеге (әзерлек юнәлеше), квалификациясе | |
| 12. Өстәмә һөнәри белем (булган очракта) һәм һөнәри белем (үткән очракта): квалификация турындагы документның төре, аның сериясе һәм номеры, документны биргән оешманың исеме, аны бирү датасы, квалификациясе | |
| 13. Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм чит телләрне белү. Нинди дәрәҗәдә (укыйсыз һәм сүзлек белән тәрҗемә итәсез, укыйсыз һәм аңлаша аласыз, иркен беләсез) | |
| 14. Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең класслы дәрәҗәсе, Юстиция класслы дәрәҗәсе, прокурор хезмәткәренең класслы дәрәҗәсе, дипломатик ранг, хәрби яисә махсус | |

| | |
|---|---|
| исем, Россия Федерациясе субъекты дәүләт граждан хезмәтенең классы дәрәҗәсе, дәүләт, муниципаль хезмәтнең квалификация разряды, муниципаль хезмәткәрнең классы дәрәҗәсе: дәрәҗә, ранг яисә исем бирү турындагы документның исеме, документның номеры һәм датасы | |
| 15. Хәрби бурычка мөнәсәбәт, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданның таныклыгы яисә хәрби билет (хәрби билет урынына бирелгән вакытлыча таныклык яисә белешмә) булу: документның төре, аның сериясе һәм номеры, документны биргән органның исеме, аны бирү датасы, хәрби учетта торучы хәрби комиссариат исеме | |
| 16. Эшләү, хезмәт итү, уку чорында рәсмиләштерелгән дәүләт серенә рөхсәт (дәүләт серенә рәсмиләштерелгән соңгы рөхсәт күрсәтелә): рөхсәт биргән органның яки оешманың исеме, рөхсәт итү рәвеше, рәсмиләштерү елы | |
| 17. Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы Паспорт (хезмәт паспортын, дипломатик паспортны да кертеп, гамәлдәге барлык паспортларның реквизитлары күрсәтелә) (булган очракта): паспортның сериясе һәм номеры, паспорт биргән органның исеме, аны бирү датасы, паспортның гамәлдә булу срогы | |

18. Хезмәткә кергәндә тутырыла:

Россия Федерациясенең тышкы разведка органнарына;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарына;

Дәүләт саклау органнарына;

Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына һәм оешмаларына;

Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарына;

Россия Федерациясе тикшерү комитетына;

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итүнең федераль органына;

Россия Федерациясе Җинаять-үтәү системасы учреждениеләренә һәм органнарына, шулай ук контракт буенча Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренә хәрби хезмәткә.

Сәяси максатлар (нинди, катнашу вакытлары (айларда һәм елларда) һәм формасы) куючы сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегендә катнашу

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

19. Чит ил агенты статусы бармы (чит ил агентлары реестрына кертү турында карар датасы) ____________________________________________________________________

20. Сезне хокукый сәләтсез дип яисә хокукый сәләте чикләнгән дип тану турында законлы көченә кергән суд карары бармы (суд карары датасы һәм номеры) ______________________________________

______________________________________________________________________________

21. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны (вазыйфаның тулы исемен) билисезме ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

22. Идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керәсезме (органның, оешманың тулы исеме һәм сезнең статусыгыз)______________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

23. Хезмәт эшчәнлеге (югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укуны, хәрби хезмәтне, берьюлы эшне, эшкуарлык эшчәнлеген һәм башкаларны кертеп).

Хәрби хезмәт турында Хәрби вазыйфа исемен, хәрби часть номерын һәм аның урнашу урынын (республика, өлкә, федераль әһәмияттәге шәһәр, автономияле өлкә, автономияле округ, торак пункт) үз эченә алган мәгълүмат, әгәр дәүләт һәм (яисә) хезмәт серен тәшкил итүче белешмәләргә кермәсә, күрсәтелә.

Оешма, орган исемнәре тулысынча үзләрендә эшләгән чорда ничек аталган булса, шулай күрсәтелә. Чит ил яки уртак оешмада йә аның вәкиллегендә эшләгән очракта оешманың ведомстводан булуы, дәүләт теркәлүе күрсәтелә

| Ай һәм ел | | Оешма, орган исеме күрсәтелгән вазыйфа | Оешманың, органның адресы |
|---|---|---|---|
| ка бул итү | эштән азат итү | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

24. Гаилә хәле (әгәр никахлашкан булсагыз, кем белән (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), никахлашу датасын, тиешле документны биргән органның исемен, аны бирү датасын, никах өзелгән очракта - никахны туктату датасын, тиешле документны биргән органның исемен, аны бирү датасын күрсәтегез)
____________________________________________________

____________________________________________________

____________________________________________________

____________________________________________________

____________________________________________________

25. Гаилә әгъзалары һәм якын туганнар: хатыныгз (ирегез), Сезнең һәм хатыныгызның (ирегезнең), әтисе, әнисе, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, уллыкка алучылар, уллыкка алынган балалар, туганнан туган булмаган абый-энеләрегез һәм апа-сеңелләрегез.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итү федераль органына хезмәткә кергәндә шулай ук элеккеге ир белән хатын турында белешмәләр күрсәтергә кирәк.

Дәүләт саклау органнарына һәм Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренә контракт буенча хәрби хезмәткә кергәндә шулай ук бер торак урында бергә яшәүче һәм (яисә) Сезнең белән теркәлгән затлар турында һәм элеккеге ир белән хатын турында белешмәләр күрсәтергә кирәк.

Әгәр гаилә әгъзалары һәм якын туганнары фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен үзгәрткән булсалар, шулай ук аларның элекке фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен күрсәтергә кирәк

| Туган-лык дәрәҗәсе | Фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу датасы һәм урыны (паспорт нигезендә күрсәтеләләр; әгәр паспорттагы мәгълүмат туу турындагы таныклыктагы мәгълүмат белән туры килмәсә, туу турындагы таныклык нигезендә өстәмә рәвештә мәгълүмат күрсәтелә) | Гражданлык | Эш, уку урыны (оешманың, органның исеме һәм адресы), вазыйфа | Яшәү урыны (теркәлү, фактта яшәү адресы; туганы үлгән очракта аның үлү датасы һәм җирләү урыны күрсәтелә) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

26. Сезнең чит илдә даими яшәүче (Россия Федерациясе дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаруга йә дәүләт серенә кертелгән белешмәләр белән эш итү вәкаләтләре бирелгән оешмаларга командировка ясауга бәйле булмаган сәбәпләр аркасында ел дәвамында Россия Федерациясеннән читтә алты айдан артык яшәүчеләр (булучылар) һәм (яисә) яшәүгә рөхсәте яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булган әтиегез, әниегез, хатыныгыз (ирегез), балаларыгыз, абыйларыгыз, апа-сеңелләрегез

| Туганлык дәрәҗәсе | Фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта) | Чит илдә булу чоры (ае һәм елы) (чит илдә даими яшәүче затларга карата күрсәтелә) | Яшәү дәүләте | Тору максаты |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

27. Җинаять җаваплылыгына тартылганмы (шул исәптән кире алынган яисә кире алынган хөкем ителү турында белешмәләр күрсәтелә)

| Россия Федерациясе Җинаять кодексының (башка законның) пункты, өлеше, статьясы | Җәзаны билгеләү датасы | Җәзаның төре, вакыты һәм (яисә) күләме |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

28. Хезмәткә кергәндә тутырыла:
Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарына;
Дәүләт саклау органнарына;
Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтенә;
Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына һәм оешмаларына;
Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарына;
Россия Федерациясе Тикшерү комитетына;
Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итүнең федераль органына;
Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренә һәм органнарына.

Эшлекле үкенү, зыян күрүче белән татулашу, искерү сроклары узу, зыянны каплау, суд штрафы билгеләү, амнистия турындагы акт яки ярлыкау акты нәтиҗәсендә йә башка нигездә җинаять җаваплылыгыннан азат ителдегезме

| Россия Федерациясе Җинаять кодексының (башка законның) пункты, өлеше, статьясы | Җинаять җаваплылыгыннан азат итү датасы | Җинаять җаваплылыгыннан азат итү нигезе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

29. Хезмәткә кергәндә тутырыла:
Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарына;
Дәүләт саклау органнарына;
Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтенә;
Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына һәм оешмаларына;
Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарына;
Россия Федерациясе Тикшерү комитетына;
Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итүнең федераль органына;
Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренә һәм органнарына.

Җинаять эше буенча шикләнелүче яки гаепләнүче булып торасызмы________________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________________________

30. Хезмәткә кергәндә тутырыла:
Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарына;
Дәүләт саклау органнарына;
Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтенә;
Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына һәм оешмаларына;
Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарына;
Россия Федерациясе Тикшерү комитетына;
Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итүнең федераль органына;
Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренә һәм органнарына, шулай ук контракт буенча Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренә хәрби хезмәткә.

Анкета тутыру көненә кадәрге ел дәвамында юри административ хокук бозган өчен (җәлеп итү датасы, нинди административ хокук бозу)суд тәртибендә административ җәзага тартылдыгызмы

____________________________________________________________________________________________

31. Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә яисә муниципаль хезмәткә кергәндә тутырыла.

Сезгә карата дисквалификация рәвешендәге административ җәза кулланылдымы (куллану датасы, ни өчен)

32. Дәүләт саклау органнарына, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итү федераль органына хезмәткә кергәндә тутырыла.

Россия Федерациясеннән читтә теркәлгән мөлкәткә милек хокукы бармы (чит дәүләтнең административ-территориаль берәмлегенең исемен күрсәтегез)

33. Хезмәткә кергәндә тутырыла:

Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарына;

Дәүләт саклау органнарына;

Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтенә;

Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына һәм оешмаларына;

Россия Федерациясенең мәҗбүри башкару органнарына;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетына;

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизацион әзерлеген тәэмин итүнең федераль органына;

Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренә һәм органнарына, шулай ук контракт буенча Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренә хәрби хезмәткә.

Спорт разряды, спорт исеме (спорт төре)

34. Сугышчан хәрәкәтләрдә, террорчылыкка каршы һәм махсус операцияләрдә, аварияләрне, һәлакәтләрне һәм табигый бәла-казаларны бетерүдә катнашу, гадәттән тыш хәл шартларында һәм коралды низаглар вакытында бурычларны үтәү (җирлек, шул исәптән Россия Федерациясеннән читтә, чорлар (айлар һәм еллар), таныклыкның сериясе һәм номеры, таныклык биргән органның исеме, аны бирү датасы)

35. Дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм мактау билгеләре

36. Яшәү урыны (теркәлү, фактта яшәү адресы) ________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

37. Контакт телефон номерлары, электрон почта адреслары (булган очракта) ________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

38. Өстәмә белешмәләр: гыйльми дәрәҗә (дипломның сериясе һәм номеры, аны биргән органның яки оешманың исеме, бирү датасы һәм урыны), гыйльми исем (аттестатның сериясе һәм номеры, аны биргән органның яки оешманың исеме, бирү датасы һәм урыны) булу, шулай ук үзегез турында хәбәр итәргә теләгән башка мәгълүмат________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

39. Россия Федерациясе дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә бәйле чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәргә сүз бирәм.

Миңа билгеле булганча, анкетада белә торып ялган мәгълүматлар күрсәтү һәм минем квалификация таләпләренә туры килмәвем Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә яки муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тартуга китерергә мөмкин.

Миңа карата тикшерү чаралары уздыруга, шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә (шул исәптән аларны автоматлаштырылган эшкәртүгә), шулай ук өченче яктан шәхси мәгълүматларымны алуга һәм тикшерү чараларын үткәрү максатларында аларны өченче якка тапшыруга ризалык бирәм.

«___»_________ 20__ел                                        Имза ___________________

Анкетада бәян ителгән фотография һәм белешмәләр тапшырылган М. документларга туры килә.
П.

«___»_________
20__ел                    ________________________________________________
(имза, исем һәм әтисенең исенең (булган очракта) беренче хәрефләре, кадрлар хезмәте (кадрлар бүлеге) хезмәткәренең фамилиясе